# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге Мәмәшир авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

07 ноябрь, 2024 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Мәмәшир авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Мәмәшир аваыл җирлегенен Мәмәшир авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк кешеләрдән, 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләрдән,18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту - Мәмәшир авылының урам-юл челтәренә вак таш салу, ремонтлау, карап тоту,вак таш сатып алу,автомобиль күперен ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (тирәннән суырта торган насослар һәм электр җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру, Мәмәшир авылын су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен

билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Мәмәшир авылында урам яктыртуны көйләү өчен, урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, ремонтлау);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Мәмәшир авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре),

(спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазландыру, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, җәен территориянең печәнен чабу, материаллар сатып алу һәм ташу);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантлары һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (җәяүлеләр күперен төзү һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

3. Әлеге карарны Мәмәшир авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәмәшир авыл җирлеге
башлыгы: И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702